# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 19 октябре №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елнын 17 октябрендә 10.00 сәгатьтә, 17 октябрендә 11.00 сәгатьтә, 17 октябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында узган гражданнар жыенының нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләренең хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Ленино авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, чапкычлар, бензотриммерлар, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (авылның сууткәргеч челтәрендә коелар төзү өчен бетон боҗралар сатып алу һәм урнаштыру, коеларда күчмә җайланмалар урнаштыру, ремонт һәм су белән тәэмин итү системасыннан агып чыгуларны бетерү, торбалар һәм өзеклекләрне ремонтлау өчен запас частьләр сатып алу һәм аларны урнаштыру, су белән тәэмин итү системасында торбаларны алыштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 414 кеше кертелгән, 267 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашкан 267 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләренең хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 600 сум

күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Ленино авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, чапкычлар, бензотриммерлар, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (авылның сүүткәргеч челтәрендә коелар төзү өчен бетон боҗралар сатып алу һәм урнаштыру, коеларда күчмә җайланмалар урнаштыру, ремонт һәм су белән тәэмин итү системасыннан агып чыгуларны бетерү, торбалар һәм өзеклекләрне ремонтлау өчен запас частьләр сатып алу һәм аларны урнаштыру, су белән тәэмин итү системасында торбаларны алыштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)» карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында ": https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32 йорт мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы

С.Ю.Питеркина